Республика Татарстан

Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.07.2023 ел Менделеевск ш. №443

Менделеевск шәһәре территориясендә
законсыз урнаштырылган капиталь булмаган
объектны сүтү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 222 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 декабрендәге 784 номерлы карары (алга таба - Тәртип) белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре территориясендә законсыз урнаштырылган капиталь булмаган төзелмәләрне, корылмаларны сүтү тәртибенә таянып карары (алга таба - Тәртип), ТР Менделеевск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан әзерләнгән 2023 елның 16 июнендәге 9 номерлы үз белдеге белән төзелгән корылма билгеләренә ия объектны карау актына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Менделеевск шәһәре, Хезмәт урамы, 1 нче йорт районында 55.896997 52.307617 координатлар чикләрендә урнашкан, җир кишәрлегенә һәм төзелгән объектка карата хокук билгели торган документлар һәм гомуми файдалану территориясе чикләрендә урнашкан үзлегеннән төзелгән капиталь булмаган объектны - хуҗалык корылмаларын җимерүне гамәлгә ашырырга. Әлеге объектның хокук иясе 2023 елның 16 июненән хәбәр ителгәннән бирле ачыкланмаган.

2. Капиталь булмаган объектны сүтү рәсми басылып чыккан көннән соң 10 эш көненнән дә иртәрәк булмаган вакытта башкарылырга мөмкин.

3. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районын төзекләндерү идарәсе» муниципаль унитар предприятиесенә катгый рәвештә 3-4 пунктлар нигезендә үз белдекле корылманы сүтү чарасын гамәлгә ашырырга.

4.Әлеге карарны "Менделеевские новости" газетасында, хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С.В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ

шәһәр хуҗалыгы буенча
җитәкче урынбасары С.В.Метальников

Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе
Н.И.Антоновская

Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царёва

ТР Менделеевск
муниципаль районы
башкарма комитетының
2023 елның 21 июлендәге
443 номерлы карарына кушымта

# Ситуацияле план

